# *Тормышыбыз бизәге сез*

**(Өлкәннәр көненә багышланган кичә.)**

**Максат.** ***Укучыларда өлкәннәргә ихтирам хисе тәрбияләү, тормышның кадерен белергә өйрәтү, аларның иҗади сәләтләрен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.***

**Хәерле көн, хөрмәтле ветераннарыбыз!**

**Бүген без монда Өлкәннәр көнен билгеләп үтәргә җыелдык. Бүген безгә мәктәбебездә төрле елларда хезмәт иткән, хәзерге вакытта лаеклы ялда булган хезмәткәрләребез килде.**

**Кадерле кунаклар! Сезне Өлкәннәр көне белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә ныклы сәламәтлек, чиксез шатлык, балаларыгызның игелеген күреп яшәвегезне телибез.**

**<u>А:</u>** **Бәйрәмегез котлы булсын,**
**Табыныгыз мул булсын,**
**Күңел шатлык белән тулсын,**
**Ял кичәгез гөрләп торсын.**

**<u>Р:</u>** **Кояш көлеп уянды да,**
**Нурларын сипте мулдан.**
**Өлкәннәр килгән мәктәпкә**
**Атлап кояшлы юлдан.**

**<u>Л:</u>** **Һәр җирдә бер хикмәт көтә,**
**Бүген гади көн түгел.**
**Бүген - Өлкәннәр бәйрәме,**
**Шуңа шатлана күңел.**

**<u>А:</u>** **Өйдән чыгып киткән чакта**
**Иртән мәктәпкә диеп,**
**Кем ул: - Исән йөр, балам, - дип,**
**Озатып кала сөеп?**
**Йә, кем булсын, кемнең шулай**
**Сүзләре татлы тагын?**
**Шулай ярата белә бит**
**Әбием генә бары.**

**<u>Җыр.</u>**

**<u>Г:</u>** **Гел яхшыга өйрәтәсез,**
**Тыңлыйбыз Сезнең сүзне,**

Һәр эштә үрнәк Сез безгә,
Хөрмәт итәбез Сезне.

**Л:** Ышаныгыз, без мәктәптә
Гел тырышып укырбыз.
Кайгы – хәсрәтләр китерми,
Таянычыгыз булырбыз.

**Кадерле Өлкәннәр!**
**Сызламасын газиз җаннарыгыз,**
**Сызласа да аяк – кулларыгыз.**
**Озын гомер бирсен Сезгә ходай**
**Рәнҗетмәсен ул һәм кызларыгыз!**

**Бүген бездә кунакта мәктәбебезнең хөрмәтле ветеран – укытучылары:**

- **Татар теле һәм әдәбияты укытучысы, укыту - тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләгән Хәтирә апа;**
- **Математика фәненнән белем биргән укытучылар Хаҗәр апа һәм Нәҗибә апа;**
- **Лаеклы ялда булуларына карамастан бүгенге көнгәчә безнең арабызда хезмәт юлларын дәвам итүче башлангыч сыйныфлар укытучысы Нәфисә апа һәм спорт буенча мәктәбебезгә бик күп җиңүләр китерүче хөрмәтле Наил абый.**

**Сезне якынлашып килүче һөнәри бәйрәмегез белән тәбрик итәбез.**
**(балалар чәчәк бәйләмнәре тапшыралар)**

**Концерт номеры:**

**Э:** Еллар үтә диеп борчылмагыз,
Еллар үтү берни түгел ул.
Сау – сәламәт булып озак яшәү –
Үзе бәхет, үзе шатлык ул.

**Бүген без шулай ук мәктәбебездә төрле елларда чисталыкны саклаучы хезмәткәрләребез Мәликә, Рәфкыя, Тәүзиха апаларга, тәмле ашлар пешерүче Фәнүзә апага, мәктәбебезне саклаучы**

**Мәсәлим абыйга рәхмәт әйтәбез. Рәхмәт сезгә тырыш хезмәтегез өчен.**

**(балалар чәчәк бәйләмнәре тапшыралар)**

**<u>Җыр.</u>**

**Ә хәзер без бер уен уйнап алырбыз. (подноста сораулар язылган кәгазь битләре).**

**Кадерле кунаклар! Бу кәгазь битләренә сораулар язылган, шул сорауларга җавап бирүегезне үтенәм.**

- **Сез беренче укытучыгызның исемен хәтерлисезме?**
- **Сез беренче сыйныфка укырга кайчан һәм кайда бардыгыз?**
- **Мәктәптә ятлаган нинди шигырьне хәтерлисез?**
- **Мәктәп елларындагы нинди вакыйганы исегездә калдырдыгыз?**
- **Сез берәр спорт төре белән шөгыльләндегезме?**
- **Сезнең яраткан вареньегыз нинди?**
- **Нинди телевизион тапшыруны яратасыз?**
- **Сезнең яраткан шөгылегез нинди?**
- **Сезнең мәктәптә яраткан фәнегез нинди иде?**
- **Сезнең оныгыгыз нинди фәнне ярата?**

**Рәхмәт кадерле кунаклар! Инде сезнең турыда без күбрәк белдек.**

**<u>Гүзәл башкаруында чегән биюе.</u>**

**<u>А:</u> - Балакаем, - ди әби,**
**- Алмакаем,- ди әби,**
**- Шикәрем син, балым син,**
**Иң кадерле җаным син.**
**Минем хөрмә җимешем,**
**Челтерәп аккан инешем...**
**Каян таба сүзләрен,**
**Тезә тәмле сүзләрен.**
**Мин алай әйтә белмим,**
**- Әбием, - дим, - әбием!**

**<u>Д:</u> Безнең заман әбиләре**

**Бар яктан да килгәннәр.**
**Мондый әбиләргә карап,**
**“Супер әби”, - дияләр.**
**Аларның белмәгәне юк,**
**Барын да булдыралар.**
**Балаларга, оныкларга**
**Иң матур үрнәк алар.**

**Кадерле ветераннар, хөрмәтле Өлкәннәр сезнең бәлки безгә, балаларга әйтер сүзләрегез бардыр.**

**Хөрмәтле ветераннар!**

**Яшәгез сез мәңге яшь булып,**
**Туган йортыгызда ямь булып.**
**Сез булсагыз сау – сәламәт,**
**Оныкларга булыр бик рәхәт.**
**Оныкларга терәк булып,**
**Яшәгез сез шатлыкта.**
**Сәламәтлек, ак бәхетләр**
**Юлдаш булсын картлыкта.**

**Күзләр җитте диеп моңаймагыз,**
**Мәңге горур булып калыгыз.**
**Кояш кебек янып яшәдегез,**
**Йолдыз кебек балкып яныгыз.**

**Җыр. “ Бәхеттә, шатлыкта”.**

**Хөрмәтле Өлкәннәребез!**

**Сездәгедәй изгелек, сездәгедәй сабырлык шулкадәр кирәк безгә. Сау – сәламәт булыгыз. Тыныч матур тормышта гомер кичерегез!**

**Ә хәзер сезне чәй табыны янына чакырабыз.**

# КОШЛАР- БЕЗНЕҢ ДУСЛАРЫБЫЗ

**Бәйрәм барышы:**

**Алып баручы:**

**Җир шарында-8600, илебездә исә 700 дән артык кош очрый. Безнең республикада исә җәй көннәрендә 200 төрдән артыграк, ә кышын 40 лап төр кошны очратырга була. Мәсәлән, чыпчык, тукран, песнәк, боҗыр, көртлек, карабүрек, саескан, ала карга, күкшә, кызылтүш һәм башкалар безнең якларда кышлыйлар.**

**1 укучы: Кыш көне без канатлы дусларыбызны онытмадык. Алар өчен җимлекләр ясап куйдык.**

**2 укучы: Песнәк тәрәз каршында,**
**Түше сары лимон күк;**
**Кара бүрек башында,**
**Юри киеп куйган күк.**

**3 укучы: Уйнаклый да талпына,**
**Шакып ала: тук, тук, тук!**
**Онытkансыз мине, ди,**
**Нигә бүген җим юк, юк!**

**4 укучы: Юк, мин кошларны онытмадым. Җимлеккә ашарга салдым да аларның туклануын күзәтеп тордым. Кошларга карап тору нинди күңелле!**

**5 укучы: Песнәк- файдалы кош. Бер песнәк җәйге айларда көненә 500-600 зарарлы бөҗәк ашый.**

**6 укучы: Сез беләсезме “Урман докторы” дип кайсы кошны атыйлар?**

**Балалар: Тукранны.**

**7 укучы: Тукран һәр агач саен**
**Тук- тук сугып карый,**
**Кошчыкның очлы борыны**
**Кирәкле эшкә ярый.**
**Агач корытучы кортларны,**
**Эзләп, чокып бетерә,**

**“Урман докторы” булып ул**
**Илгә файда китерә.**

**Алып баручы: Кошлар һавада очарга җайлашканнар. Шуңа күрә алар кеше аягы басмаган урыннарда да яшиләр. Таулар, урманнар, диңгезләр аша очу кошлар өчен бик үк авыр түгел. Мәсәлән, илебезнең Европа өлешендә яшәүче авыл һәм шәһәр карлыгачларының Африканың көньягына очып китүе, аларның Һиндстанда кышлавы билгеле булды. Хәзәр, яз җиткәч, алар туган җирләренә кире әйләнеп кайталар. Безнең якны сагынып кайтучы кошларның сез кайсыларын беләсез һәм күргәнегез бар?**

**Балалар: Кара карга, сыерчык, тургай, торна, карлыгач, сандугач, бытбылдык, аккош, шәүлегән, кыр казы, кыр үрдәге...**

**8 укучы: Кошлар- табигать күрке. Шуңа күрә шагыйрьләребез, аларга багышлап, шигырьләр, композиторларыбыз гүзәл әсәрләр иҗат итәләр.**

**(җыр: “Кәккүк” Ш. Мөдәрис сүзләре, Ә. Бакиров музыкасы).**

**9 укучы: Калкулыклар кардан арындылар,**
**Язгы сулар шаулап актылар.**
**Әкрен генә дымсу җилләр исте,**
**Күтәрелде җирдән ак томан.**

**10 укучы: Кояш нурын сипте җир өстенә**
**Исте йомшак җилләре,**
**Кошлар кайта: сагындырган**
**Туган үскән илләре.**

**11 укучы: Көннәрен юлда үткәреп,**
**Куанышып очалар,**
**Канатларына күтәреп,**
**Яз китерә ич алар.**

**12 укучы: Ямьле яз башланды. Иң беренче булып яз хәбәрчесе кара каргалар очып кайтты. Беләсезме, алар**

**безнең якларга кайтканда тәүлегенә 50 километр чамасы юл үтәләр.**

**13 укучы:**

**Кара каргалар да кешеләргә файда китерә. Җәен бер кара карга чама белән 8 меңгә кадәр бөҗәк ашый .**

**14 укучы: Язын ерак- ераклардан**

**Очып килде каргалар,**
**Тал башына зур бер шәһәр**
**Тезеп куйдылар алар.**

**15 укучы: Без каршы алдык аларны**
**Үз итеп, сөеп,**
**Диңгез, чүлләрне исән- сау**
**Кичкәнсез диеп.**

**16 укучы: Нинди матур, иркен саф һавалы**
**Нинди күркәм безнең ягыбыз.**
**Кайда бар соң бездәгедәй язлар?**
**Гүзәл дә соң туган ягыбыз.**

**(җыр: "Яз шатлыгы" җыры (Г. Насрый сүзләре, Җ. Фәйзи музыкасы) башкарыла)**

**17 укучы: Исәнмесез, кошкайлар,**
**Безнең якын дускайлар.**
**Карлыгачлар, актүшләр,**
**Сандугачлар, тургайлар.**

**18 укучы: Сыерчыктан Вилгә**
**Телеграмма килгән:**
**"Сезгә кунак булып**
**Киләм,- дигән,- тиздән...**
**Бик сагындым сезне,**
**Якты йөзегезне,**
**Каршы аласыз шул**
**Бик яратып безне".**

**19 укучы: Әйе, сыерчык- безнең иң яраткан кошыбыз. Ул үзенең матур итеп сайравы белән безне сокландыра һәм бөҗәкләрне, лайлыч әкәм- төкәмне ашап зур файда китерә.**

**( җыр: “Сыерчык” Г. Лотфи сүзләре, И. Шәмсетдинов музыкасы.)**

**20 укучы: Иртә язда басу һәм далалар өстендә- биек бер кош оча. Ул нинди кош икән?**

**Балалар: Ул- тургай.**

**21 укучы: Тургай канат кага- кага өздереп сайравы белән һәркемне таң калдыра, шулай итеп, ул игенчене кырга чакыра.**

**(җыр: “Тургай килде” Г. Латыйпов сүзләре, Ш. Мәҗитов музыкасы).**

**22 укучы: Нинди якты уйлар уйлап,**
**Кыр казлары, кыйгак- кыйгак,**
**Болын буйлап, кырлар буйлап**
**Кайта безгә язны зурлап.**

**23 укучы: Тезелешеп гаскәр кебек,**
**Ераклардан илләр гизеп,**
**Кычкыралар: “Кайттык урап,**
**Исәнмесез, кыйгак- кыйгак”**

**24 укучы: “Яз көне кыр казлары биектән очып үткәләр, иген уңар”,- ди халык.**

**25 укучы: Яз җиткәч, безнең якларга карлыгачлар очып кайта. Алар, ару- талуны белмичә, көне буе ауда йөриләр. Хәзер сез карлыгач турында җыр ишетерсез.**

**(җыр: “Карлыгач” Г. Тукай сүзләре, З. Хәбибуллин музыкасы).**

**26 укучы: Күгәрченем,очып уйна,**
**Нурга коенып уйна!**
**Канат кагып кыйгачлатып,**
**Зәңгәр киңлекне буйла!**

**27 укучы: Күгәрченем, очкан чакта**
**Талмыймы канатларың?**
**Беләмсең туган илемнең**
**Тынычлык яратканын.**
**Барысы бергә: Күгәрченем гөрлә- гөрлә,**

**Гөрлә бәхетле илдә.**
**Безнең белән бергә-бергә**
**Гөрләшеп яшә син дә!**

**28 укучы: Кошларның файдасы гаять зур. Алар үсемлек орлыкларын тараталар, чәчәкләрне серкәләндерәләр.**

**29 укучы: Канатлы дусларыбызны сакларга, аларның ояларын туздырмаска, күкәйләрен ватмаска кирәк.**

**30 укучы: Яшелчә һәм җимеш бакчаларына сыерчык оялары куйыйк.**

**31 укучы: Канатлы дусларыбызны һәм ярдәмчеләребезне саклыйк һәм яклыйк.**

**32 укучы: Хуш киләсез, кошкайлар,**
**Сайрагыз көнен- төнен.**
**Кайда ошый?**
**Сайлагыз,**
**Җир- сулар бик киң безнең.**

**Алып баручы: Әйдәгез, хәзер мин сезгә кошлар турында табышмаклар, башваткычлар әйтәм, ә сез җавабын табып карагыз.**

**1.Үзе яшел үләндәй,**
**Койрыгы чиккән keләмдәй.**
**Чуклы калфак кигән ул,**
**Бик ерактан килгән ул.**

**2. Гөрли- гөрли җырлый ул.**
**Кызыл читек кия ул.**
**Күлмәкләре күгелҗем,**
**Татулыкны сөя ул.**

**3. Кайсы кошның балтасы борынында?**

**4. Кайсы кош бик тиз йөгерә?**
**5. Кайсы кош ауга төнлә генә чыга? Ни өчен?**
**6. Кайсы кошның исеменнән бер иҗекне алсаң, кар өеме исеме була?**
**7. Кайсы кошның квартирасы кар астында?**

**8. Кайсы кошның балалары әниләрен белми?**
**9. Күп кенә кошлар кыш көне ни өчен торак йортлар тирәсенә җыелалар?**
**10. Сыерчыклар кеше ясаган оядан башка тагын кайларда оялыйлар?**
**11. Карлыгачлар ояларын кайларда, ничек ясыйлар?**
**12. Ерткыч кошларга нинди кошлар керә?**
**13. Ни өчен барлык кошлар да көз көне көньккa китмиләр?**
**Бәйрәмне тәмәмлау.**

# ТАБЫШМАКЛАР КИЧӘСЕ



**МАКСАТ: балаларның уйлау сәләтен үстерү, аларны тапкырлыкка, зирәклеккә өйрәтү, күзәтүчән булырга, образлар ярдәмендә фикер йөртергә өйрәтү.**

**Катнашалар: алып баручы, Айзирәк, Тапкырҗан, балалар.**

**Бәйрәм барышы:**

**Алып баручы:**
**Бәйрәм бүген, бездә була**
**Табышмаклар кичәсе,**
**Бу кичәгә Тапкырҗан да,**
**Айзирәк тә киләсе.**
**Шаянҗан да катнашачак-**
**Ул да хәбәр җибәргән,**
**Өч командага бүленик.**
**Алар килгәнгә кадәр.**

**Табышмак сөючеләр өч төркемгә бүленеп басалар. Һәр команда үзенә капитан сайлый. Шул вакыт иңнәренә калын сумкалар аскан Тапкырҗан, Айзирәк һәм Шаянҗан керә. (Тапкырҗан белән Айзирәкнең сумкасына "Табышмаклар", ә Шаянҗанныкына "Мәзәк- табышмаклар" дип язылган).**

**Шаянҗан:**
**Сезгә кунакка килдек без-**
**Мин, Тапкырҗан, Айзирәк,**
**Табышмак кичәсе ясап,**
**Уйнап алыйк әзерәк.**
**Айзирәк:**
**Уйныйк әле, уйлыйк әле,**
**Сынатыштан булмасын;**
**Кичә барганда берәү дә**
**Авыз йомып тормасын.**
**Тапкырҗан:**
**Мин дә алып килдем, дуслар,**

**Бик күп табышмак, мәзәк;**
**Кайсы төркем үз җавабын**
**Әйтер икән тизрәк.**
**(Тапкырҗан табышмак язылган билетларны, сумкасыннан алып укый-укый,беренче төркемдәгеләргә өләшә).**

**1. Икәүдер умырткасы,**
**Унаудыр кабыргасы,**
**Атлам-атлам арасы,**
**Атлап өскә барасы (баскыч).**

**2. Сәнәге бар маңгаенда,**
**Турсыгы бар түшендә,**
**Тәмле ак эчемлек йөртә**
**Турсыгының эчендә (кәҗә, сыер).**

**3. Яшел келәм өстендә**
**Утлы күмерләр көйри,**
**Кулга алсаң пешерми,**
**Авызга алсаң эри( каен җиләге).**

**4. Старты юк- йөгертә.**
**Гармоны юк- биетә,**
**Куллары юк- чеметә,**
**Монсы Нәрсә? Кем әйтә? (суык)**

**5. Аңа беркем су тутырмый,**
**Үзе һич сусыз тормый,**
**Үзе акмый, үзе артмый,**
**Яры тулы су саклый (күл).**

**6. Яучы да түгел үзе,**
**Җанлы да түгел үзе.**
**Аргы ярны бирге ярга**
**Кавыштыра ул үзе (басма).**

**7. Тамырында алма була,**
**Сабакларында- йөзем.**
**Алмаларын гына аның**
**Җыеп алалар көзен (бәрәңге).**

**Тапкырҗан табышмаклар язылган билетларны өләшеп чыгуга. Икенче төркем алдына Айзирәк килеп баса.**

**Айзирәк:**

**Тапкырҗаннан калышырга**
**Исәбем юк минем дә,**
**Табышмаклар тапшырырга**
**Килдем мин дә бирегә.**
**(Шуннан соң ул да икенче төркемдәгеләрнең һәрберсенә, укый-укый, табышмаклар өләшә).**

**1. Җәй көне сарыны кия,**
**Кыш көне- тунның агын,**
**Чуарын киеп ала ул**
**Күзләрен һәм язларын (куян).**

**2. Үзе туптай түгәрәк,**
**Өстендә буй-буй күлмәк**
**Эчендә була аның**
**Алсу төстә бал- ширбәт (карбыз0.**

**3. Иртә- кичен җәелә**
**Урман-кырга, басуга;**
**Кояш карый башлагач,**
**Пар булып юкка чыга (томан).**

**4. Берсе- яшел келәм тукый,**
**Берсе- сарыга мана,**
**Берсе- ак мамыгын түши**
**Ә берсе- җыеп ала.(ел фасыллары).**

**5. Маңгаенда мөгезе бар.**
**Боргаласаң үкерә.**
**Менеп атлансаң биленә,**
**Җилдән җитез йөгерә (мотоцикл).**

**6. Күле тулы төнбоек-**
**Көндезләрен юк була,**
**Кич җиттеме- җемелдәп**
**Тора торган ут була( йолдызлар).**

**7. Яшь чагында башына**
**Кия сары эшләпә,**
**Картайгач йоны коела,**
**Кала бөтенләй шәрә (Тузганак).**

**Айзирәк табышмакларын өләшеп бетерүгә, өченче төркем алдына Шаянҗан килеп баса.**

**Шаянҗан:**

**Тапкырҗан да, Айзирәк тә**
**Өләште бүләкләрен,**
**Минем дә сезгә бар, дуслар,**
**Табышмак- мәзәкләрем.**

**Шаянҗан өченче төркемдәге укучыларга үзенең табышмакларын укый- укый өләшә.**

**1. Пыр-пыр итеп китәр кош,**
**Күккә менеп китәр кош,**
**Сусаганда су да түгел,**
**Девон маен эчәр кош.**
**Бу ни була? Исем куш! (самолёт)**

**2. Элпә канат, билле кош,**
**Чәчәкләргә кунар кош,**
**Яхшы эшне эшләр кош.**
**Ачуланса- тешләр кош,**
**Бу ни була? Исем куш! (бал корты)**

**3. Чырык- чырык итәр кош,**
**Тырык- тырык итәр кош,**
**Бер урыннан, бер урынга**
**Сикереп кенә китәр кош.**
**Бу ни була? Исем куш! (чикерткә).**

**4. Чабар булса, тыр- пыр ат**
**Авыр йөкләр тартыр ат,**
**Девон маен ашар ат,**
**Бу нинди ат? Исем тап! (йөк машинасы).**

**5. Тимербаскычлар буенча**
**Корыч айгыр чаба.**
**Томырылып чапканда**
**Ялын сыртка сала (поезд).**

**6. Кешеләргә булмаса да**

**Җәбер- золым кылганы,**
**Чүкеч белән кыйныйлар**

**Баш түбәсен аның (кадак).**
**7. Акбүз түгел, җирән түгел**
**Аның кигән толыбы,**
**Диңгезче күлмәге кебек**
**Бик килешле- буй-буйлы.**
**Туганягы- җылы як.**
**Я, ул нәрсә? Әйтеп бак!(зебра).**

**Шаянҗан табышмакларны өләшеп бетергәч, алып баручы катнашучыларның җавапларын анализларга керешә.**

**Алып баручы:**
**Ярышка старт алырга**
**Һәммәгез әзер сыман,**
**Җавапларны миңа килеп**
**Әйтсен һәрбер капитан.**

**Өч команданың да капитаны, алып баручы янына килеп, үз командаларына бирелгән табышмакларның җавапларын әйтә.**

**Алып баручы:**
**Канәгатьмин җаваплардан,**
**Барсы да дөрес тулы;**
**Тапкырҗанның елмаюы**
**Аңлатып тора шуны.**
**Безнең бүгенге кунаклар-**
**Шаян, тапкыр, Айзирәк.**
**Хәзер инде аларга да**
**Табышмак әйтү кирәк.**

**(Беренче команда капитаны Тапкырҗанга, укый- укый, үзенең табышмаклар язылган карточкасын бирә)**

**1. Күрешергә кулы юк,**
**Сөйләшергә теле юк,**
**Аның белән күрешмәгән,**
**Киңәшмәгән кеше юк(китап).**

**2. Буй- буй сузылган юллары**

**Барсы да туры, зәңгәр,**
**Энәсез һәм җепсез генә**
**Чигәләр аңа сүзләр (дәфтәр).**

**3. Күлләре бар – суы юк.**
**Чүлләре бар- комы юк.**
**Тик анда исемнәре-**
**Юк анда җисемнәре (карта)**

**4. Дөньяның бар кисәге**
**Өстендә аның тора4**
**Юк хәзинәсенең чиге,**
**Булса да бер шар гына (глобус).**

**Беренче команда капитаны табышмакларны әйтеп бетерүгә, икенче команда капитаны Айзирәк янына килеп баса һәм аңа, укый- укый, үзенең табышмаклар язылган карточкасын бирә.**

**1. Кеше түгел,юк аның**
**Ни кулы, ни авызы.**
**Укучының зирәклеген**
**Күрсәтәдер ул үзе(“5”ле билгесе).**

**2. Миңа бик охшап тора**
**Ике япьле сәнәк,**
**Якын дусларым минем-**
**Тырышлык һәм сәләт(“4”ле билгесе).**

**3. Аягы булмаса да,**
**Ул бик кызу йөри,**
**Авызы булмаса да,**
**Төрле телләрдә сөйли(радио).**

**4. Үзе бик әрсез,**
**Бөкре, ямьсез,**
**Ялкауга юлдаш.**
**Ул ни, беләмсез? (“2” ле билгесе).**

**Икенче команда табышмакларын әйтеп бетерүгә, өченче команда капитаны Шаянҗан янына килеп баса һәм аңа, укый- укый, үзенең 4 табышмак билетын бирә.**

**1. Авызы юк, бар теле,**

**Туны һәм төймәләре;**
**Шул төймәләргә кагылсаң,**
**Кузгата күңелләрне (гармун).**

**2. Җәясе юк, угы юк.**
**Ә шулай да ук ата.**
**Тирә-юньне яктыртып,**
**Уңга-сулга ут ата(Яшен).**

**3.Җәясе юк, угы юк,**
**Ә шулай да ук ата,**
**Тирә-юньне яктыртып,**
**Уңга- сулга ут ата(яшен).**

**4. Бер ояда алты дус,**
**Алтысында алты төс,**
**Шушы дуслар барысы да**
**Башкаралар бер үк эш;**
**Юк аларда энәләр,**
**Ләкин чигү чигәләр (буяу карандашлары).**

**Тапкырҗан, айзирәк һәм Шаянҗан, алып баручы янына килеп, үзләренә бирелгән табышмакларның җавапларын әйтәләр.**

**Бәйрәмне йомгаклау.**

**Алып баручы:**
**Кунаклар да җавапларын**
**Әйттеләр дөрес итеп,**
**Инде хәзер кичәбезнең**
**Ахыры килә җитеп.**

**Кунаклар табышмак сөючеләр тапкыр, зирәк җаваплар өчен бер-берсен котлыйлар. Шуннан соң кунаклар хор белән:**

**Кичә бик күңелле булды,**
**Тәмле булды сыегыз,**

**Бүләк итеп безгә тагын**
**Табышмаклар җыегыз,-**
**дип чыгып китәләр.**

# КОШЛАР- БЕЗНЕҢ ДУСЛАРЫБЫЗ

**Бәйрәм барышы:**

**Алып баручы:**
**Җир шарында-8600, илебездә исә 700 дән артык кош очрый. Безнең республикада исә җәй көннәрендә 200 төрдән артыграк, ә кышын 40 лап төр кошны очратырга була. Мәсәлән, чыпчык, тукран, песнәк, божыр, көртлек, карабүрек, саескан, ала карга, күкшә, кызылтүш һәм башкалар безнең якларда кышлыйлар.**

**1 укучы: Кыш көне без канатлы дусларыбызны онытмадык. Алар өчен җимлекләр ясап куйдык.**

**2 укучы: Песнәк тәрәз каршында,**
**Түше сары лимон күк;**
**Кара бүрек башында,**
**Юри киеп куйган күк.**

**3 укучы: Уйнаклый да талпына,**
**Шакып ала: тук, тук, тук!**
**Оныткансыз мине, ди,**
**Нигә бүген җим юк, юк!**

**4 укучы: Юк, мин кошларны онытмадым. Җимлеккә ашарга салдым да аларның туклануын күзәтеп тордым. Кошларга карап тору нинди күңелле!**

**5 укучы: Песнәк- файдалы кош. Бер песнәк җәйге айларда көненә 500-600 зарарлы бөҗәк ашый.**

**6 укучы: Сез беләсезме “Урман докторы” дип кайсы кошны атыйлар?**

**Балалар: Тукранны.**

**7 укучы: Тукран һәр агач саен**
**Тук- тук сугып карый,**

**Кошчыкның очлы борыны**
**Кирәкле эшкә ярый.**
**Агач корытучы кортларны,**
**Эзләп, чокып бетерә,**
**“Урман докторы” булып ул**
**Илгә файда китерә.**

**Алып баручы: Кошлар һавада очарга җайлашканнар. Шуңа күрә алар кеше аягы басмаган урыннарда да яшиләр. Таулар, урманнар, диңгезләр аша очу кошлар өчен бик үк авыр түгел. Мәсәлән, илебезнең Европа өлешендә яшәүче авыл һәм шәһәр карлыгачларының Африканың көньягына очып китүе, аларның Һиндстанда кышлавы билгеле булды. Хәзәр, яз җиткәч, алар туган җирләренә кире әйләнеп кайталар. Безнең якны сагынып кайтучы кошларның сез кайсыларын беләсез һәм күргәнегез бар?**

**Балалар: Кара карга, сыерчык, тургай, торна, карлыгач, сандугач, бытбылдык, аккош, шәүлегән, кыр казы, кыр үрдәге...**

**8 укучы: Кошлар- табигать күрке. Шуңа күрә шагыйрьләребез, аларга багышлап, шигырьләр, композиторларыбыз гүзәл әсәрләр иҗат итәләр.**

**(җыр: “Кәккүк” Ш. Мөдәрис сүзләре, Ә. Бакиров музыкасы).**

**9 укучы: Калкулыклар кардан арындылар,**
**Язгы сулар шаулап актылар.**
**Әкрен генә дымсу җилләр исте,**
**Күтәрелде җирдән ак томан.**

**10 укучы: Кояш нурын сипте җир өстенә**
**Исте йомшак җилләре,**
**Кошлар кайта: сагындырган**
**Туган үскән илләре.**

**11 укучы: Көннәрен юлда үткәреп,**
**Куанышып очалар,**

**Канатларына күтәреп,**
**Яз китерә ич алар.**

**12 укучы: Ямьле яз башланды. Иң беренче булып яз хәбәрчесе кара каргалар очып кайтты. Беләсезме, алар безнең якларга кайтканда тәүлегенә 50 километр чамасы юл үтәләр.**

**13 укучы:**

**Кара каргалар да кешеләргә файда китерә. Җәен бер кара карга чама белән 8 меңгә кадәр бөҗәк ашый .**

**14 укучы: Язын ерак- еракларддан**

**Очып килде каргалар,**
**Тал башына зур бер шәһәр**
**Тезеп куйдылар алар.**

**15 укучы: Без каршы алдык аларны**
**Үз итеп, сөеп,**
**Диңгез, чүлләрне исән- сау**
**Кичкәнсез диеп.**

**16 укучы: Нинди матур, иркен саф һавалы**
**Нинди күркәм безнең ягыбыз.**
**Кайда бар соң бездәгедәй язлар?**
**Гүзәл дә соң туган ягыбыз.**

**(җыр: “Яз шатлыгы” җыры (Г. Насрый сүзләре, Җ. Фәйзи музыкасы) башкарыла)**

**17 укучы: Исәнмесез, кошкайлар,**
**Безнең якын дускайлар.**
**Карлыгачлар, актүшләр,**
**Сандугачлар, тургайлар.**

**18 укучы: Сыерчыктан Вилгә**
**Телеграмма килгән:**
**“Сезгә кунак булып**
**Киләм,- дигән,- тиздән...**
**Бик сагындым сезне,**
**Якты йөзегезне,**

**Каршы аласыз шул**
**Бик яратып безне”.**

**19 укучы: Әйе, сыерчык- безнең иң яраткан кошыбыз. Ул үзенең матур итеп сайравы белән безне сокландыра һәм бөҗәкләрне, лайлыч әкәм- төкәмне ашап зур файда китерә.**

**( җыр: “Сыерчык” Г. Лотфи сүзләре, И. Шәмсетдинов музыкасы.)**

**20 укучы: Иртә язда басу һәм далалар өстендә- биек бер кош оча. Ул нинди кош икән?**

**Балалар: Ул- тургай.**

**21 укучы: Тургай канат кага- кага өздереп сайравы белән һәркемне таң калдыра, шулай итеп, ул игенчене кырга чакыра.**

**(җыр: “Тургай килде” Г. Латыйпов сүзләре, Ш. Мәҗитов музыкасы).**

**22 укучы: Нинди якты уйлар уйлап,**
**Кыр казлары, кыйгак- кыйгак,**
**Болын буйлап, кырлар буйлап**
**Кайта безгә язны зурлап.**

**23 укучы: Тезелешеп гаскәр кебек,**
**Ераклардан илләр гизеп,**
**Кычкыралар: “Кайттык урап,**
**Исәнмесез, кыйгак- кыйгак”**

**24 укучы: “Яз көне кыр казлары биектән очып үткәләр, иген уңар”,- ди халык.**

**25 укучы: Яз җиткәч, безнең якларга карлыгачлар очып кайта. Алар, ару- талуны белмичә, көне буе ауда йөриләр. Хәзер сез карлыгач турында җыр ишетерсез.**

**(җыр: “Карлыгач” Г. Тукай сүзләре, З. Хәбибуллин музыкасы).**

**26 укучы: Күгәрченем,очып уйна,**
**Нурга коенып уйна!**

**Канат кагып кыйгачлатып,**
**Зәңгәр киңлекне буйла!**
**27 укучы: Күгәрченем, очкан чакта**
**Талмыймы канатларың?**
**Беләмсең туган илемнең**
**Тынычлык яратканын.**
**Барысы бергә: Күгәрченем гөрлә- гөрлә,**

**Гөрлә бәхетле илдә.**
**Безнең белән бергә-бергә**
**Гөрләшеп яшә син дә!**

**28 укучы: Кошларның файдасы гаять зур. Алар үсемлек орлыкларын тараталар, чәчәкләрне серкәләндерәләр.**

**29 укучы: Канатлы дусларыбызны сакларга, аларның ояларын туздырмаска, күкәйләрен ватмаска кирәк.**

**30 укучы: Яшелчә һәм җимеш бакчаларына сыерчык оялары куйыйк.**

**31 укучы: Канатлы дусларыбызны һәм ярдәмчеләребезне саклыйк һәм яклыйк.**

**32 укучы: Хуш киләсез, кошкайлар,**
**Сайрагыз көнен- төнен.**
**Кайда ошый?**
**Сайлагыз,**
**Җир- сулар бик киң безнең.**

**Алып баручы: Әйдәгез, хәзер мин сезгә кошлар турында табышмаклар, башваткычлар әйтәм, ә сез җавабын табып карагыз.**

**1.Үзе яшел үләндәй,**
**Койрыгы чиккән келәмдәй.**
**Чуклы калфак кигән ул,**
**Бик ерактан килгән ул.**

**2. Гөрли- гөрли җырлый ул.**
**Кызыл читек кия ул.**
**Күлмәкләре күгелҗем,**

**Татулыкны сөя ул.**

**3. Кайсы кошның балтасы борынында?**

**4. Кайсы кош бик тиз йөгерә?**

**5. Кайсы кош ауга төнлә генә чыга? Ни өчен?**

**6. Кайсы кошның исеменнән бер иҗекне алсаң, кар өеме исеме була?**

**7. Кайсы кошның квартирасы кар астында?**

**8. Кайсы кошның балалары әниләрен белми?**

**9. Күп кенә кошлар кыш көне ни өчен торак йортлар тирәсенә җыелалар?**

**10. Сыерчыклар кеше ясаган оядан башка тагын кайларда оялыйлар?**

**11. Карлыгачлар ояларын кайларда, ничек ясыйлар?**

**12. Ерткыч кошларга нинди кошлар керә?**

**13. Ни өчен барлык кошлар да көз көне көньккa китмиләр?**

**Бәйрәмне тәмәмлау.**

# ТАБЫШМАКЛАР КИЧӘСЕ



**МАКСАТ: балаларның уйлау сәләтен үстерү, аларны тапкырлыкка, зирәклеккә өйрәтү, күзәтүчән булырга, образлар ярдәмендә фикер йөртергә өйрәтү.**

**Катнашалар: алып баручы, Айзирәк, Тапкырҗан, балалар.**

**Бәйрәм барышы:**

**Алып баручы:**
**Бәйрәм бүген, бездә була**
**Табышмаклар кичәсе,**
**Бу кичәгә Тапкырҗан да,**
**Айзирәк тә киләсе.**
**Шаянҗан да катнашачак-**
**Ул да хәбәр җибәргән,**
**Өч командага бүленик.**
**Алар килгәнгә кадәр.**

**Табышмак сөючеләр өч төркемгә бүленеп басалар. Һәр команда үзенә капитан сайлый. Шул вакыт иңнәренә калын сумкалар аскан Тапкырҗан, Айзирәк һәм Шаянҗан керә. (Тапкырҗан белән Айзирәкнең сумкасына “Табышмаклар”, ә Шаянҗанныкына “Мәзәк- табышмаклар” дип язылган).**

**Шаянҗан:**
**Сезгә кунакка килдек без-**
**Мин, Тапкырҗан, Айзирәк,**
**Табышмак кичәсе ясап,**
**Уйнап алыйк әзерәк.**

**Айзирәк:**
**Уйныйк әле, уйлыйк әле,**
**Сынатыштан булмасын;**
**Кичә барганда берәү дә**
**Авыз йомып тормасын.**

**Тапкырҗан:**
**Мин дә алып килдем, дуслар,**
**Бик күп табышмак, мәзәк;**
**Кайсы төркем үз җавабын**
**Әйтер икән тизрәк.**

**(Тапкырҗан табышмак язылган билетларны, сумкасыннан алып укый-укый,беренче төркемдәгеләргә өләшә).**

**1. Икәүдер умырткасы,**
**Унаудыр кабыргасы,**
**Атлам-атлам арасы,**
**Атлап өскә барасы (баскыч).**

**2. Сәнәге бар маңгаенда,**
**Турсыгы бар түшендә,**
**Тәмле ак эчемлек йөртә**
**Турсыгының эчендә (кәҗә, сыер).**

**3. Яшел келәм өстендә**
**Утлы күмерләр көйри,**
**Кулга алсаң пешерми,**
**Авызга алсаң эри( каен җиләге).**

**4. Старты юк- йөгертә.**
**Гармоны юк- биетә,**
**Куллары юк- чеметә,**
**Монсы Нәрсә? Кем әйтә? (суык)**

**5. Аңа беркем су тутырмый,**
**Үзе һич сусыз тормый,**
**Үзе акмый, үзе артмый,**
**Яры тулы су саклый (күл).**

**6. Яучы да түгел үзе,**
**Җанлы да түгел үзе.**
**Аргы ярны бирге ярга**
**Кавыштыра ул үзе (басма).**

**7. Тамырында алма була,**
**Сабакларында- йөзем.**
**Алмаларын гына аның**
**Җыеп алалар көзен (бәрәңге).**

**Тапкырҗан табышмаклар язылган билетларны өләшеп чыгуга. Икенче төркем алдына Айзирәк килеп баса.**

**Айзирәк:**

**Тапкырҗаннан калышырга**
**Исәбем юк минем дә,**

**Табышмаклар тапшырырга**
**Килдем мин дә бирегә.**
**(Шуннан соң ул да икенче төркемдәгеләрнең һәрберсенә, укый-укый, табышмаклар өләшә).**

**1. Җәй көне сарыны кия,**
**Кыш көне- тунның агын,**
**Чуарын киеп ала ул**
**Күзләрен һәм язларын (куян).**

**2. Үзе туптай түгәрәк,**
**Өстендә буй-буй күлмәк**
**Эчендә була аның**
**Алсу төстә бал- ширбәт (карбыз0.**

**3. Иртә- кичен җәелә**
**Урман-кырга, басуга;**
**Кояш карый башлагач,**
**Пар булып юкка чыга (томан).**

**4. Берсе- яшел келәм тукый,**
**Берсе- сарыга мана,**
**Берсе- ак мамыгын түши**
**Ә берсе- җыеп ала.(ел фасыллары).**

**5. Маңгаенда мөгезе бар.**
**Боргаласаң үкерә.**
**Менеп атлансаң биленә,**
**Җилдән җитез йөгерә (мотоцикл).**

**6. Күле тулы төнбоек-**
**Көндезләрен юк була,**
**Кич җиттеме- җемелдәп**
**Тора торган ут була( йолдызлар).**

**7. Яшь чагында башына**
**Кия сары эшләпә,**
**Картайгач йоны коела,**
**Кала бөтенләй шәрә (Тузганак).**

**Айзирәк табышмакларын өләшеп бетерүгә, өченче төркем алдына Шаянҗан килеп баса.**

**Шаянҗан:**

**Тапкырҗан да, Айзирәк тә**
**Өләште бүләкләрен,**
**Минем дә сезгә бар, дуслар,**
**Табышмак- мәзәкләрем.**

**Шаянҗан өченче төркемдәге укучыларга үзенең табышмакларын укый- укый өләшә.**

**1. Пыр-пыр итеп китәр кош,**
**Күккә менеп китәр кош,**
**Сусаганда су да түгел,**
**Девон маен эчәр кош.**
**Бу ни була? Исем куш! (самолёт)**

**2. Элпә канат, билле кош,**
**Чәчәкләргә кунар кош,**
**Яхшы эшне эшләр кош.**
**Ачуланса- тешләр кош,**
**Бу ни була? Исем куш! (бал корты)**

**3. Чырык- чырык итәр кош,**
**Тырык- тырык итәр кош,**
**Бер урыннан, бер урынга**
**Сикереп кенә китәр кош.**
**Бу ни була? Исем куш! (чикерткә).**

**4. Чабар булса, тыр- пыр ат**
**Авыр йөкләр тартыр ат,**
**Девон маен ашар ат,**
**Бу нинди ат? Исем тап! (йөк машинасы).**

**5. Тимербаскычлар буенча**
**Корыч айгыр чаба.**
**Томырылып чапканда**
**Ялын сыртка сала (поезд).**

**6. Кешеләргә булмаса да**
**Җәбер- золым кылганы,**
**Чүкеч белән кыйныйлар**

**Баш түбәсен аның (кадак).**
**7. Акбүз түгел, җирән түгел**
**Аның кигән толыбы,**
**Диңгезче күлмәге кебек**
**Бик килешле- буй-буйлы.**
**Туганягы- җылы як.**
**Я, ул нәрсә? Әйтеп бак!(зебра).**
**Шаянҗан табышмакларны өләшеп бетергәч, алып баручы катнашучыларның җавапларын анализларга керешә.**
**Алып баручы:**
**Ярышка старт алырга**
**Һәммәгез әзер сыман,**
**Җавапларны миңа килеп**
**Әйтсен һәрбер капитан.**
**Өч команданың да капитаны, алып баручы янына килеп, үз командаларына бирелгән табышмакларның җавапларын әйтә.**
**Алып баручы:**
**Канәгатьмин җаваплардан,**
**Барсы да дөрес тулы;**
**Тапкырҗанның елмаюы**
**Аңлатып тора шуны.**
**Безнең бүгенге кунаклар-**
**Шаян, тапкыр, Айзирәк.**
**Хәзер инде аларга да**
**Табышмак әйтү кирәк.**
**(Беренче команда капитаны Тапкырҗанга, укый- укый, үзенең табышмаклар язылган карточкасын бирә)**
**1. Күрешергә кулы юк,**
**Сөйләшергә теле юк,**
**Аның белән күрешмәгән,**
**Киңәшмәгән кеше юк(китап).**
**2. Буй- буй сузылган юллары**

**Барсы да туры, зәңгәр,**
**Энәсез һәм җепсез генә**
**Чигәләр аңа сүзләр (дәфтәр).**

**3. Күлләре бар – суы юк.**
**Чүлләре бар- комы юк.**
**Тик анда исемнәре-**
**Юк анда җисемнәре (карта)**

**4. Дөньяның бар кисәге**
**Өстендә аның тора4**
**Юк хәзинәсенең чиге,**
**Булса да бер шар гына (глобус).**

**Беренче команда капитаны табышмакларны әйтеп бетерүгә, икенче команда капитаны Айзирәк янына килеп баса һәм аңа, укый- укый, үзенең табышмаклар язылган карточкасын бирә.**

**1. Кеше түгел,юк аның**
**Ни кулы, ни авызы.**
**Укучының зирәклеген**
**Күрсәтәдер ул үзе(“5”ле билгесе).**

**2. Миңа бик охшап тора**
**Ике япьле сәнәк,**
**Якын дусларым минем-**
**Тырышлык һәм сәләт(“4”ле билгесе).**

**3. Аягы булмаса да,**
**Ул бик кызу йөри,**
**Авызы булмаса да,**
**Төрле телләрдә сөйли(радио).**

**4. Үзе бик әрсез,**
**Бөкре, ямьсез,**
**Ялкауга юлдаш.**
**Ул ни, беләмсез? (“2” ле билгесе).**

**Икенче команда табышмакларын әйтеп бетерүгә, өченче команда капитаны Шаянҗан янына килеп баса һәм аңа, укый- укый, үзенең 4 табышмак билетын бирә.**

**1. Авызы юк, бар теле,**

**Туны һәм төймәләре;**
**Шул төймәләргә кагылсаң,**
**Кузгата күңелләрне (гармун).**

**2. Җәясе юк, угы юк.**
**Ә шулай да ук ата.**
**Тирә-юньне яктыртып,**
**Уңга-сулга ут ата(Яшен).**

**3.Җәясе юк, угы юк,**
**Ә шулай да ук ата,**
**Тирә-юньне яктыртып,**
**Уңга- сулга ут ата(яшен).**

**4. Бер ояда алты дус,**
**Алтысында алты төс,**
**Шушы дуслар барысы да**
**Башкаралар бер үк эш;**
**Юк аларда энәләр,**
**Ләкин чигү чигәләр (буяу карандашлары).**

**Тапкырҗан, айзирәк һәм Шаянҗан, алып баручы янына килеп, үзләренә бирелгән табышмакларның җавапларын әйтәләр.**

**Бәйрәмне йомгаклау.**

**Алып баручы:**
**Кунаклар да җавапларын**
**Әйттеләр дөрес итеп,**
**Инде хәзер кичәбезнең**
**Ахыры килә җитеп.**

**Кунаклар табышмак сөючеләр тапкыр, зирәк җаваплар өчен бер-берсен котлыйлар. Шуннан соң кунаклар хор белән:**

**Кичә бик күңелле булды,**
**Тәмле булды сыегыз,**
**Бүләк итеп безгә тагын**
**Табышмаклар җыегыз,-**
**дип чыгып китәләр.**